АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЧУРАКАЙ

АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

423746, Чуракай авылы, Совет ур., 69 йорт

АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

423746, село Чуракаево, ул. Советская, дом 69

КАРАР РЕШЕНИЕ

от 27.11.2020 г. № 11

**Чуракай авыл җирлеге территориясендә үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану турында**

06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25,1,56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 27.11.2020 елгы гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә Чуракай авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Чуракай авыл җирлеге территориясендә 2021 нче елда, 1 нче төркем инвалидларыннан,кондезге булектэ укучы студентлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 500 (биш йөз) сум күләмендә бер тапкыр түләүләр кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә.:

*** ритуаль хезмәтләр оештыру һәм күмү урыннарын карап тоту:**
Зират йортларын ремонтлау;
*** җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру:**
Сабантуй урынындагы коймаларны янарту;
*** автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:**
Авылларда юлларны ремонтлау (кардан чистарту, грейдерлау)
*** җирлек чикләрендә халыкны су, электр белән тәэмин итүне оештыру:**
су торбаларын алыштыру**, су** чыганакларын рэсмилэштеру, чыгымнарын тэмин иту ;

Чуракай, Иске Әгъбәз авылларында урам утлары чыгымнарын тәэмин иту;

2. Актаныш муниципаль районы Чуракай авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында гражданнар җыены нәтиҗәләрен игълан итәргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында " Чуракай авыл җирлеге» бүлегендә урнаштырырга.

Чуракай Советы Башлыгы

авыл җирлеге башлыгы Р.Р.Хайдаров